**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.10.2024 **Чирмешән авылы** № 357

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда сатып алына торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен түләүне кичектереп түләү срогын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы һәм «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында, һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендәге һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан сатып алына торган арендалана торган мөлкәт өчен түләүне кичектереп түләү срогы күчемсез мөлкәт өчен 5 (биш) ел һәм күчемле мөлкәт өчен 3 (өч) ел тәшкил итә.

2. Сатып алына торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен түләү тәртибен (бер мәртәбә яисә өлешләп түләү), шулай ук арендалана торган мөлкәт сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгән чикләрдә өлешләп түләү срогын сайлау хокукы кече яисә урта эшкуарлык субъектына карый.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.М.Җамалетдинов